# КАРАР

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге составына керүче Балык Бистәсе штп. торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 4 декабре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә ярашлы рәвештә гражданнар җыенының 13.11.2020, 16.11.2020, 18.11.2020, 20.11.2020, 23.11.2020, 25.11.2020, 27.11.2020, 30.11.2020, 02.12.2020 числоларда

“Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм тыл хезмәтчәннәреннән гайре, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм, тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге:

1) Балык Бистәсе штп. территориясендә уңайлылык булдыруны оештыру: урамнарны, паркларны һәм скверларны төзекләндерү, карап тору;

2) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өлкәсендә: Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы территориясендә янгын гидрантлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру;

3) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне (уңайлылык тудыруны) оештыру өлкәсендә: Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урам күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру

эшләрен башкару өчен тотуга Сез ризамы?

“ЯКЛАП” “КАРШЫ”

дигән сорау (мәсьәлә) буенча узган этаплары нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында гражданнар җыенының узган этаплары нәтиҗәләре буенча җыенның йомгаклау беркетмәсенә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә **6143 (алты мең бер йөз кырык өч)** гражданнар җыенында катнашучы кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **3139 (өч мең бер йөз утыз тугыз)** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ЯКЛАП” позициясе өчен 2164 (ике мең бер йөз алтмыш дүрт) гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;
“КАРШЫ” позициясе өчен 975 (тугыз йөз җитмеш биш) җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге составына керүче Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы торак пунктында гражданнар җыенын **узган** дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан һәм тыл хезмәтчәннәреннән гайре, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм, тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге:

1) Балык Бистәсе штп. территориясендә уңайлылык булдыруны оештыру: урамнарны, паркларны һәм скверларны төзекләндерү, карап тору;

2) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өлкәсендә: Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы территориясендә янгын гидрантлары күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру;

3) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне (уңайлылык тудыруны) оештыру өлкәсендә: Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы территориясендә урам күрсәткечләрен әзерләү һәм урнаштыру

эшләрен башкару өчен тотуга Сез ризамы?”

дигән сорау (мәсьәлә) буенча карарны **“кабул ителгән”** дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башлыгы И.Р. Тажетдинов